**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 8 декабрендәге 4294 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 8 августындагы 2589 номерлы карары белән расланган Минск урамы, Җиңү проспекты һәм Вознесенский тракты чикләрендәге территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 8 августындагы 2589 номерлы карары белән расланган Минск урамы, Җиңү проспекты һәм Вознесенский тракты чикләрендәге территорияне планлаштыру проектына, әлеге карарга кушымта нигезендә планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чykканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 8 декабрендәге
4294 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 8 августындагы 2589 номерлы карары белән расланган Минск урамы, Җиңү проспекты һәм Вознесенский тракты чикләрендәге территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары күрсәтелгән территорияне планлаштыру проекты сызымын әлеге үзгәрешләргә кушымта нигезендә редакцияләргә.

2. Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмәдә:

2.1. 2 нче таблицада 5-9 нчы юлларны яңа редакциядә бирергә һәм түбәндәге эчтәлекле 10 нчы юл белән тулыландырырга:

| **Инфраструктура объектлары сыйдырышлылыгына ихтыяж** | **Күрсәткеч** | |
|---|---|---|
| | **1 нче участок** | **2 нче участок** |
| «Машина урыннары саны | 560, шул исәптән | 222, шул исәптән |
| даими саклау өчен, машина урыны | 449 | 178 |
| вакытлыча саклау өчен, кунаклар өчен, машина урыны | 81 | 32 |
| эчкә кертеп төзелгән, кушып төзелгән һәм эчкә кертеп-кушып төзелгән биналар өчен, машина урыны | 20 | 6 |
| мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре өчен, машина урыны | 4 | 3 |
| электр энергиясе җыю җайланмалары өчен, машина урыны | 6 | 3» |

2.2. 3 нче таблицада 3 нче юлны түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Капиталь төзелеш объектлары характеристикалары** | **Планлаштыру структурасы элементы чикләрендәге билгеләнеше** | |
|---|---|---|
| | **1 нче участок** | **2 нче участок** |
| «Торак йортларда катларның максималь саны, җир өстендәге катлар саны | 31 | 31» |

2.3. 4 нче «Төзелеш» таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

| «Билгеләнеше | Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары нигезендә капиталь төзелеш объектлары | | |
|---|---|---|---|
| | **күп катлы торак төзелеше** | **мәктәпкәчә учреждениеләр** | **инженерлык инфраструктурасы объектлары** |
| 1 нче участок | 1 данә | 1 данә | 3 данә |
| 2 нче участок | 1 данә | 1 данә | 3 данә» |

2.4. 4 нче таблицага искәрмәне түбәндәге редакциядә бирергә:

«Искәрмә. Планлаштырыла торган объектларның эшләве һәм гражданнарның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле инженерлык инфраструктурасы объектларының һәм башка объектларның саны һәм урнашу урыны проектлаштыруның алдагы стадияләрендә төгәлләштерелергә мөмкин»;

2.5. 5 нче «Җир кишәрлекләре өчен капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең чик параметрлары» таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

| «Билгеләнеше | Рөхсәт ителгән файдалану төре атамасы | Объектлар | Чик параметрлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **Җир кишәрлеге чикләреннән ераклык (м)** | | | **Төзелеш проценты (%)** | **Торак фонды төзелеше тыгызлыгы (мең кв.м/га)** | **Яшелләндерү проценты (%)** |
| | | | **П** | **Б** | **З** | | | |
| 1 нче участок | Стилобатлы күпкатлы торак төзелеше | - | 0 | 0 | 0 | 80 | 22,2 | 27,5 |
| 2 нче участок | Стилобатлы күпкатлы торак төзелеше | - | 0 | 0 | 0 | 80 | 23,16 | 24,4» |

2.6. 6 нчы таблицада 1, 2, 3, 5, 6, 7, 9, 10 нчы юлларны түбәндәге редакциядә бирергә:

| Территорияне планлаштыру сызымында зона номеры | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы төре | Урнаштыру зонасы мәйданы (гектар) | Капиталь төзелеш объектларында катларның максималь саны | Торак фондының (фатирларның) максималь гомуми мәйданы (мең кв.м) | Торак фондының (фатирларның) максималь тыгызлыгы (мең кв.м/гектар) | Халык саны (кеше) | Йорт эченә кертеп төзелгән иҗтимагый билгеләнештәге биналарның гомуми мәйданы (мең кв.м) | Рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары | Урнаштырыла торган объектларның тасвирламасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1 | 1 – Күпкатлы торак төзелеше | 2,28 | 31 | 44,74 | 22,2 | 1492 | 1,82 | 2.6; 3.1.1 | Йорт эченә кертеп төзелгән торак булмаган биналар белән күпфатирлы торак төзелеше |
| 2 | 1 – Күпкатлы торак төзелеше | 1,02 | 31 | 17,78 | 23,16 | 593 | 0,578 | 2.6; 3.1.1 | Йорт эченә кертеп төзелгән торак булмаган биналар белән күпфатирлы торак төзелеше |
| 3 | 5 – Иҗти-магый-эшлекле билгеләнештәге | 2,61 | Билгеләнмәгән | - | - | - | - | 3.0; 3.1.1 | Сәүдә һәм коммерция билгеләнешендәге объектлар, офислар өчен һәм административ биналар» |
| «5 | 12 – Транспорт инфраструктурасы | 0,1 | Билгеләнмәгән | - | - | - | - | 4.9.1.3, 3.1.1 | Автомобиль юу урыны |
| 6 | 5 – Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге | 2,5 | Билгеләнмәгән | - | - | - | - | 3.0; 3.1.1 | Сәүдә һәм коммерция билгеләнешендәге объектлар, офислар өчен һәм административ биналар |
| 7 | 11 – Инженерлык инфраструктурасы объектлары | 0,02 | - | - | - | - | - | 3.1.1 | Җылылык белән тәэмин итү объекты» |

| Территорияне планлаштыру сызымында зона номеры | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы төре | Урнаштыру зонасы мәйданы (гектар) | Капиталь төзелеш объектларында катларның максималь саны | Торак фондының (фатирларның) максималь гомуми мәйданы (мең кв.м) | Торак фондының (фатирларның) максималь тыгызлыгы (мең кв.м/гектар) | Халык саны (кеше) | Йорт эченә кертеп төзелгән иҗтимагый билгеләнештәге биналарның гомуми мәйданы (мең кв.м) | Рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары | Урнаштырыла торган объектларның тасвирламасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «9 | 12 – Транспорт инфраструктурасы | 1,18 | Билгеләнмәгән | - | - | - | - | 2.7.1; 3.1.1 | 499 машина урынына исәпләнгән паркинг |
| 10 | 12 – Транспорт инфраструктурасы | 0,29 | Билгеләнмәгән | - | - | - | - | 4.9.1.1; 3.1.1 | Ягулык салу станциясе» |

2.7. «Транспорт инфраструктурасы характеристикалары» бүлегендә «557» санын «560» санына, «221» санын «222» санына алыштырырга.

3. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмәдә:

3.1. икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:


«1 нче участок – күпкатлы торак төзелеше: инженерлык челтәрләренә тоташтыруны, территорияне төзекләндерүне дә кертеп, 44 738,95 кв.м торак (транспорт чараларын даими саклау өчен парковкалар – 449 машина урыны, кунаклар өчен парковкалар – 81 машина урыны, электр энергиясе җыю станцияләре – 6 машина урыны), 1822,43 кв.м коммерция билгеләнешендәге торак булмаган биналар (объект яны парковкалары – 20 машина урыны), 125 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе (объект яны парковкалары – 4 машина урыны)»;

3.2. өченче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2 нче участок – күпкатлы торак төзелеше: инженерлык челтәрләренә тоташтыруны, территорияне төзекләндерүне дә кертеп, 17 780,90 кв.м торак (транспорт чараларын даими саклау өчен парковкалар – 178 машина урыны, кунаклар өчен парковкалар – 32 машина урыны, электр энергиясе җыю станцияләре – 3 машина урыны), 578,32 кв.м коммерция билгеләнешендәге торак булмаган биналар (6 машина урыны), 50 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе (объект яны парковкалары – 3 машина урыны)».

# I. Чертеж проекта планировки территории с указанием границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, с указанием зон планируемого размещения объектов капитального строительства.

Приложение к изменениям, вносимым в проект планировки территории в границах ул.Минская, пр.Победы и тракта Вознесенский, утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 08.08.2025 №2589




| Функциональное зонирование территории | |
|---|---|
| 1 | планируемая зона размещения многоэтажной жилой застройки (девять этажей и более) |
| 5 | существующая зона размещения объектов общественно-делового назначения |
| 21 | территория общего пользования (УДС) |
| 11 | существующий объект инженерной инфраструктуры |
| 12 | существующая зона размещения объектов транспортной инфраструктуры |
| ① | порядковый номер зоны размещения |
| 1 | вид зоны размещения объектов капитального строительства |
| 2,28 | площадь зоны размещения (га) |
| 12.0.1 | коды видов разрешенного использования |
| 44,74 | максимальная общая площадь жилого фонда (тыс. кв.м.) |
| 31 | максимальная этажность(этажей) |
| н.у. | параметр (характеристика) не устанавливается |
| | существующая сохраняемая застройка |

| Условные обозначения | |
|---|---|
| **Границы территорий, линии регулирования застройки** | |
| | граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории |
| красная линия | действующая красная линия улично-дорожной сети |
| | граница земельного участка |
| | публичный сервитут |
| | очередность планируемого развития территории |
| | линия регулирования застройки |
| | технический коридор инженерных коммуникаций и сооружений |
| | Ориентировочное расположение проектируемой трансформаторной подстанции |
| | Ориентировочное расположение проектируемой насосной станции |
| | Ориентировочное расположение проектируемых локальных очистных сооружений |

